**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлегенең Иске Суыксу авылында гражданнар җыены карары**

15.11.2022 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлегенең Иске Суыксу авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2023 елда Иске Суыксу авыл җирлегенең Иске Суыксу авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Иске Суыксу авылы юлларын төзекләндерүгә юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Иске Суыксу авыл җирлегенең Иске Суыксу авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Иске Суыксу авыл җирлеге башлыгы _________ М.М. Дәүләтшин

Халык җыены секретаре _________ Э.Ф. Билалова